ГЛАВА НИКИФОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Карла Маркса, д.3, с. Никифорово,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422166

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НИКИФОРОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Карл Марксур., 3 нче йорт, Никифорово авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422166

тел.(факс): (85563) 2-42-38; e-mail: Nikifor..Mam@tatar.ru, www: mamadysh.tatarstan.ru

Постановление  Карар

№1  20.02.2023 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Башлыгынын 2012 елның 1 августындагы 1номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Мамадыш районы прокурорының 2023 нче елның 31 мартындагы 02-08-02-2023 номерлы протесты, "Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында" 2009 елның 09 февралендәге 8-ФЗ номерлы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 ноябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2022 елның 14 июлендәге N 270-ФЗ федераль законнар, Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Башлыгынын 2012 елның 1 августындагы "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны оештыру тәртибе турында" Нигезләмәне раслау хакында" 1 нче номерлы карарына (алга таба-Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Әлеге Карарга Кушымтаның 8.12 пунктында “Интернет челтәрендә” сүзләрен “рәсми сайтларда” сүзләренә алмаштырырга;

1.2 Әлеге Карарга Кушымтаның 9.6 пунктында "җирле үзидарә органнарының" сүзләрен “җирле үзидарә органнарының һәм ведомство буйсынуындагы оешмаларның" сүзләренә алмаштырырга, “хезмәткәрләр" сүзләреннән соң “ведомство карамагындагы оешмаларның хезмәткәрләре” сүзләрен өстәргә;

1.3 Әлеге Карарга Кушымтаның 6 пунктындагы 4 пунктчасында “җирле үзидарә органнары” сүзләреннән соң “һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар” сүзләрен өстәргә;

1.4 Әлеге Карарга Кушымтаның 3.1 пунктына “һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар” сүзләрен өстәргә;

1.5 Әлеге Карарга Кушымтаның 5.1 пунктындагы 4 пунктчасында "җирле үзидарә органнарының, аларның вазифаи затларының" сүзләрен “җирле үзидарә органнарының һәм ведомство буйсынуындагы оешмаларның, әлеге органнарның һәм оешмаларның вазифаи затларының" сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Никифорово авыл җирлеге башлыгы С.Н.Степанов